
МБГББУ " ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУА ШӘҺӘРЕ 5 НЧЕ ГИМНАЗИЯ"
МӘКТӘП ГАЗЕТАСЫ

# ТАМЧЫ

№2-2025


*Кыш - ел фасылының иң салкыны булса да, ябалак-ябалак яуган карлары, тәрәзәдәге бизәкләре, бәсле агачлары белән күңелне җылыта, күзләрне иркәли.*

*Ни дисәң дә, кышкы табигать искиткеч матур инде. Кышкы урманда син үзеңне әкияти илендә кебек хис итәсең. Гүзәллекне тасвирларга сүзләр генә җитмәс. Табигать оста рәссам шул!*













**ЯҢА ЕЛ** – *һәркемнең иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәренең берсе. Бәйрәмгә санаулы көннәр калып бара, дуслар! Әмма бу бәйрәм турында без күп беләбезме соң? Яңа ел турында иң кызыклы фактлар белән сезне таныштырырга булдык.*

🎄*Яңа елны бәйрәм итә башлау безнең эрага кадәрге 3 меңьеллыкка – Месопотамиягә барып тоташа. Вавилон халкыннан иудейлар, аннары греклар аша бу вакыйга Көнбатыш Европага кадәр килеп җитә. Аннары инде Җир шарының башка илләренә тарала.*

*Яңа елны бәйрәм итү вакыты төрлечә булган. Аны язын да, җәй көне дә, көзен дә, без гадәтләнгәнчә кыш көне дә бәйрәм иткәннәр. Хәзерге вакытта исә күпчелек илләрдә Яңа елны 31 декабрьдән 1 гыйнварга каршы төндә бәйрәм итәләр.*



## "Чыршы" турында кызыклы фактлар

🎄 Чыршы "иң музыкаль" агач - аны күп кенә музыка кораллары ясауда кулланалар.

🎄Чыршы агачы 400-600 ел яши.

## Чыршы уенчыклары турында берничә кызыклы факт

❄Беренче чыршы уенчыклары ашый торган булган. Ягъни чыршыны элек алмалар, чикләвекләр һәм печенье белән бизәгәннәр.

❄Бөек Ватан сугышында чыршы уенчыкларын газета, тозлы камыр, чыбык, бинт, тукыма һәм металл кисәкләреннән ясаганнар.

❄Шарлар формасындагы чыршы уенчыклары идеясе алма уңмаган елда туган. Алмаларны, киләсе ел уңыш китерсен өчен, чыршыга элгәннәр.

## ГИМНАЗИЯБЕЗДӘ ЯҢА ЕЛ КИЧӘЛӘРЕ ГӨРЛӘП УЗДЫ




**Дуслар!** Без сезне якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйбыз! Яңа ел символы – горур Ат үз арбасында барыбызга да җитәрлек итеп исәнлек-саулык, уңышлар, шатлык-куанычлар салып килсен!

Каникулларда буш вакытта карар өчен түбәндәге балалар киноларын тәкъдим итәбез:










## «Пушкин картасы» н яңадан рәсмиләштерергә кирәк

***<u>2026 елдан «Пушкин картасы» программасының банк-операторы ВТБ банкы булачак.</u>***

Картадан туктаусыз файдалану өчен, аны алдан ук ВТБ банкына барып яңадан чыгартырга кирәк. Моны агымдагы елның 28 декабренә кадәр «Госуслуги Культура» кушымтасында яисә Почта банкы һәм ВТБ офисларында һәм кушымталарында эшләргә мөмкин, дип искәртә ТР Мәдәният министрлыгы матбугат хезмәте.

«Гаилә» милли проектына кергән «Пушкин картасы» 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге яшьләргә театрларга, музейларга, концертларга, күргәзмәләргә һәм кинога бушлай йөрергә мөмкинлек бирә. Ел саен картага 5 мең сум өстәлә: 2 мең сумга кадәр киносеансларга сарыф итәргә була, калганы – теләсә нинди мәдәни вакыйгалар өчен куелган.

2025 елда калган акча киләсе елга күчерелми, шуңа күрә алардан 31 декабрьгә кадәр файдаланырга кирәк. Билетларны алдан сатып алырга мөмкин-шул исәптән 2026 елда узачак чараларга да.

# ӘДӘБИ БИТ

## 2026 ел Татарстанда –Тукай елы



2026 елның 26 апрелендә бөек татар шагыйре, әдәби тәнкыйтьче һәм публицист Габдулла Тукайның (1886-1913) тууына 140 ел тула.

Шул уңайдан безнең гимназиябездә дә декабрь аенда «Безнең йөрәкләрдә син, Тукай!» дип аталган әдәби кичә үтте. 9-в сыйныф укучылары Г. Тукайның әсәрләрен укыдылар, язучыбызның иҗаты турындагы сорауларга җаваплар бирделәр.


Без Тукайның яшендәй яшьнәп үткән кыска гомер юлы, ул калдырган иҗади мирас, аның яшәү үрнәген күз алдыннан уздырып сокланабыз һәм Бөек Тукаебыз алдында баш иябез. Бөтен уй-гамәлләребез белән Тукай рухына лаек булырга тырышабыз. Аның шигырьләре күңелләрдә дәрт уята, шифа өсти, аклыкка-сафлыкка, тугрылыкка өнди, хезмәткә көч бирә. Тукаебызны зур горурлык хисләре белән искә алабыз. Тукай рухы күңелләребездә мәңге яшәр!







## Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевка 95 ел



Мөхәммәт Мәһдиев — иҗат юлын әдәбиятчы һәм әдәби тәнкыйтьче булып башлый. Аспирантурада укыган елларында ул татар иҗтимагый фикер үсеше, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть тарихы, халык авыз иҗатын фәнни өйрәнү мәсьәләләре белән кызыксына башлый. 1960нчы еллар дәвамында республика матбугаты битләрендә шул темаларга багышланган бер төркем мәкаләләрен бастыра. «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә» һәм «Бәхилләшү» повестьлары өчен ул 1990 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була, 1993 елда исә халыкчан әдәби иҗаты өчен аңа Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Указы белән «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелә.

"Без - 41 ел балалары" повесте аны укучыга ныклап таныта. Аннан соң М.Мәһдиевнең бер-бер артлы әсәрләре дөнья күрә. Укытучы, остаз, тәнкыйтьче, язучы, галим Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләре бүген дә яратылып укыла, иҗаты өйрәнелә.

# КОШЛАРНЫ БЕРГӘЛӘП АШАТЫЙК!

Ел саен, кышкы чорга аяк баскач, “**Кошларны ашатыгыз”** дип исемләнгән акция старт ала. Безнең гимназия укучылары да ел саен бу акциядә актив катнаша.

Дуслар, кышын без нәни дусларыбыз – кошлар турында онытмаска тиеш. Салкыннарда аларга ризык табу бик авыр. Шуңа күрә җимлекләр корып, анда ашарга кую мөһим.

Азыкка килгәндә кошларга бераз гына көнбагыш, тары ярмасы, ак ипи салсаң – шул җитә. Ә менә дөге, арпа ярмасы кебек коры ярмаларны кошларга бирергә кирәкми. Ашап бетермәгән ботканы яки гарнирны исә курыкмыйча бирә аласыз. Боткага май салып болгатсагыз, тагын да яхшы. Ипинең агын гына бирергә тырышыгыз. Кара ипи кошларның эчәклегендә әчи, шуңа да файдасына караганда, зыяны күбрәк. Терлек мае да (сало) әйбәт, әмма ул тозлы булмасын.

**Яхшылыкны бергә эшлик!** Җимлекләрне пластик бутылкадан, кәгазь тартмадан да ясап була. Болар барысы да кыен эшләр түгел.

















**Бирем.**
Кошларны атагыз. Сезнең ишегалдында бу кошларның кайсылары яши? Ә сез кошларга җимлекләр ясыйсызмы?

**СЫНАМЫШЛАР**

**Кошлар кар өстенә төшсә, көннәр җылыта.**
**Кара карга килгәч, бер айдан кар китәр.**
**Карлыгач килгәч, борчак чәчәргә була.**
**Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килер.**
**Әгәр торналар берәм-берәм килсәләр, җәй яхшы була.**

**Татарча-русча сүзлек**

| | |
|---|---|
| карлыгач-ласточка, | коршун – тилгән |
| воробей – чыпчык, | куропатка – кыр тавыгы |
| ворон – козгын, | ласточка – карлыгач |
| ворона – карга, | тетерев – көртлек |
| цапля – челән, | дрозд – миләш чыпчыгы |
| зяблик – кызылтүш, | стриж – яр карлыгачы |

*Мөхәррир-Гайнетдинова Э. Т.*

*Газета өчен материал туплаучылар һәм текстны җыючылар: 6,8 нче сыйныф укучылары*

*Безнең адрес: Буа шәһәре, Г. Исхакый урамы, 29*